**Республика Татарстан**
**Совет Верхне-Чершилинского сельского поселения Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы**

---

**РЕШЕНИЕ**

**КАРАР**

15.12.2025

№ 12

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Югары Чыршылы авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турындагы
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында" 03.10.2025 елгы 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман муниципаль районының «Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы:

1. Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының 2022 елның 15 февралендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә кертергә (Советның 25.11.2022 елгы 20 номерлы, 22.02.2023 елгы 1 номерлы, 05.04.2023 елгы 8 номерлы карарлары редакциясендә) 09.08.2023 № 11, 24.11.2023 № 14, 29.12.2023 № 21, 27.03.2024 № 2, 24.06.2024 № 10, 02.11.2024 № 13, 22.11.2024 № 19) түбәндәге үзгәрешләр:

2.5 пунктның 2,3 абзацлары. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә::

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу - вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен; югары белем яисә урта һөнәри белем булу - авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.".

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге советы рәисе — Р.М.Гилева